Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№20 (113)

26 июнь 2014 ел



Влад Михневский фотосы

# КФУның алтын фонды

Җиһанда җәй. Юкә чәчәк аткан чак. КФУны тәмамлаучы чыгарылыш курс студентларының да яшьлеге шау чәчәктә. Тиздән алар зур тормышка аяк басачак. «Яшьлек – тәвәккәл, аның югалту, авырлыклар тәҗрибәсе юк. Алдагы көннәрен хыялы яктысында гына күрә ул», – дип язды Шәүкәт Галиев. Киләчәктә шушы якты хыялларны тормышка ашыру өчен, университетта алган белем-тәҗрибә төп терәк булыр.

## Вакыйгалар эзеннән

**23 ИЮНЬ** көнне ректор **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Җыелыш контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм атналык вакыйгалар турында административ эшчәнлек буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ**ның чыгышы белән башланды. Аннан соң КФУның Н.И.Лобачевский ис. лицей директоры **Е.СКОБЕЛЬЦЫНА** һәм «КФУның IT-лицее» лицей-интернат директоры **Т.СӘМЕРХАНОВ** чыгарылыш сыйныф укучыларының имтиханга әзерлеге һәм нәтиҗәләр турында сөйләделәр. Җитәкчеләрнең сүзләренчә, укучылар имтиханнарны яхшы һәм югары балларга тапшырганнар. Алга таба ректорат вәкилләре Конкурентлылыкка сәләтлелек программасының барышы турында фикер алыштылар. Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор **М.САФИУЛЛИН** әлеге программага бәйле чаралар белән таныштырды.

• • • •

**23-24 ИЮНЬ** көннәрендә **КФУ**-да яңа функциональ материаллар җитештерү һәм метаматериалларны куллану мәсьәләсенә багышланган **ЛЕКЦИЯЛӘР ЦИКЛЫ ОЕШТЫРЫЛДЫ**. Беренче лекция нанофоника һәм плазмониканың асылын аңлатуга багышланды.

• • • •

**24 ИЮНЬ** көнне «Заречье» спорт-сәламәтләндерү лагеренда Татарстан яшь геологларының **I РЕСПУБЛИКА АЧЫК КЫР ОЛИМПИАДАСЫ БАШЛАНДЫ**. Олимпиадада Татарстаннан 26 команда һәм Кырым республикасының Бакчасарай районы командасы көч сынашачак. Профильле смена барышында балалар өчен укыту курслары, олимпиада биремнәрен үтәү, күңел ачу чаралары да каралган.

• • • •

**24 ИЮНЬ** көнне КФУның Алабуга институтында **ҖӘЙГЕ ИКЪТИСАД МӘКТӘБЕ** үз эшен башлап җибәрде. Россия һәм чит ил галимнәре 5 көн дәвамында җәмгыять, социаль челтәр, икътисади үсешнең төрлелеге турында фикер алышачак.

• • • •

Шушы көннәрдә **«КФУ ТУРЫНДАГЫ ИҢ ЯХШЫ ПРЕЗЕНТАЦИЯ»** конкурсына йомгак ясалды. Аның нәтиҗәләрен ректорат утырышында игълан иттеләр. Конкурста барлыгы **23 ПРОЕКТ** катнашкан. Ректор И.Гафуров җиңүчеләргә грамоталар һәм истәлекле бүләкләр тапшырды. Гран-при иясе – ГКhСФИ иҗат төркеме: А.Никитин, Т.Никитина, Э.Гайсина, А.Петров. Беренче урынны исә ФhМБИ студенты Р.Семьянинов яулады. Икенче урында – ХМТhКӨ институты студентлары Ш.Урунбаев, Т.Гатауллин, А.Байтуриннан торган иҗат төркеме. 3 урынга ГКhСФИ институты хезмәткәре Т.Куншина лаек булды.

• • • •

Күптән түгел Казан университетының юридик факультетында КФУ һәм Юстус Либих исемендәге университетларының юридик факультетлары арасындагы хезмәттәшлек килешүе кысаларында **«ХАЛЫКАРА ХОКУККА РОССИЯ ҺӘМ ГЕРМАНИЯ КАРАШЫ»** яшьләр мәктәп-конференциясе булды. Түгәрәк өстәлдә халыкара гуманитар хокук, агрессия квалификациясенә халыкара-хокукый караш мәсьәләләре турында фикер алыштылар. Катнашучылар өчен ТР Югары суды һәм Дәүләт Советына экскурсия дә оештырылды.

• • • •

Казан университеты Тарихы музее директоры **С.ПИСАРЕВА** император Александр I нигез салган Казан университеты тарихын һәм гореф-гадәтләрен саклаганы һәм яктыртканы өчен **«БӨТЕН ХАЛЫК БАТЫРЛЫГЫ ЮБИЛЕЕ. 1613 – 2013» МЕДАЛЕ** белән **БҮЛӘКЛӘНДЕ.** Әлеге бүләк бөек княгиня Мария Владимировна Романова тарафыннан тәкъдим ителгән.

*МәгълүматКФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Заман таләбе

Ринат МИНИГАЛИЕВ



Влад Михневский фотосы

Шушы көннәрдә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында Чехия Республикасының Көньяк-Морав крае губернаторы җитәкчелегендәге делегация булып китте.

# Татарлар – чех телен, ә чехлар – татар телен?

Кунакларның максаты Казан халыкара лингвистика үзәге эшчәнлеге белән танышудан һәм КФУ белән Көньяк-Морав халыкара мәгариф үзәге арасында хезмәттәшлек турында килешү төзүдән гыйбарәт иде.

Делегацияне КФУ ректоры **И.Гафуров**, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Р.Җамалетдинов, Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты директоры **Р.Хәйретдинов** каршы алды.

Чехия кунаклары институтның телләргә өйрәтү өчен махсус җиһазландырылган кабинетларында булдылар. «Ана теле» проекты җитәкчесе **К.Фәтхуллова** татар теленә өйрәтү онлайн мәктәбе проектын гамәлгә ашыру турында сөйләде. Ул губернаторга рус һәм инглиз телле кешеләргә татар теленә өйрәтә торган татар, рус, инглиз телендәге аудиокурслы дәреслек бүләк итте. **Михаил Гашекта** бу проект зур кызыксыну уятты һәм киләсе очрашуга ул: «Татар телен өйрәнеп киләчәкмен, кирәк булса, имтихан да бирермен», – дип шаяртты.

Очрашу хезмәттәшлек турында килешү документына КФУ ректоры И.Гафуров һәм Көньяк-Морав халыкара мәгариф үзәге директоры Милош Шифалдның кул куюы белән тәмамланды. Бу килешү буенча Казан шәһәре югары уку йортлары студентларына бушлай чех теленә өйрәтү, Чехия тарихы, мәдәнияте белән бәйле чаралар үткәрү каралган.

• Мөнбәр



# Тәүге җиңүчеләр

Алинә САДЫЙКОВА

20 июнь көнне университет тарихында тәүге мәртәбә уздырылган КФУның студентлар газетасы конкурсы җиңүчеләрен тәбрикләү тантанасы булды.

Конкурста биш татар һәм тугыз рус телендә чыккан газеталар катнашты. Алар – барысы да уку йортыбызда студентлар инициативасы белән иҗат итеЛә торган хезмәтләр. Әйтергә кирәк, араларында электрон версиядә дә чыга торганнары бар икән.

Җиңүчеләрне билгеләү дәрәҗәле жюри өчен җиңел булмады, чөнки һәрбер газета да үзенчәлекле, креатив һәм яшьләр рухы белән сугарылган. Жюри составында ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары, ТР Журналистлар Союзы рәисе **Р.Ратникова**, КФУның Медиа-Үзәк директоры **И.Кәримов**, Телетапшыру һәм тележитештерү кафедрасы мөдире **Р.Даутова**, «Казан» журналы редакторы **Ю.Балашов**, «Российская газета»ның республикабыздагы филиалы мөхәррире **Г.Аристова**, «Ялкын» журналы мөхәррире **Й.Миңнуллина** һәм Казанның танылган фотографы **А.Гайнетдинов** бар иде.

Татар телендә тәкъдим ителгән басмалар арасында җиңүче итеп ФиМБИның Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге проекты билгеләнде. Аны филология фәннәре кандидаты Г.Камалиева җитәкли. Рус телендәге басмалар арасында исә Гран-прига Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтының «Include» газетасы лаек дип табылды. Беренче урын – ГКһСФИның журналистика бүлеге **«Стужурка»** электрон газетасына, икенче урын – КФУның Н.И.Лобачевский ис. лицейның **«ЛиГа»**сына, өченче урын А.М.Бутлеров ис. химия институтының **«Хи.жи.на»** басмаларына бирелде. Аларның барысына да кубок, дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Төп призлардан кала, аерым номинацияләр дә каралган иде. «Автор фотосы» номинациясендә **Д.Әүһадиевага** («Стужурка» газетасы) тиңнәр табылмады, ә **А.Нуриева** («ЛиГа» газетасы) исә иң яхшы корреспондент дип табылды. «Кузгатылган темаларның актуальлеге» номинациясендә **«Стужурка»** һәм татар телендә **«Заман. XXI»** газеталары җиңү яулады. «Иң яхшы дизайнлы газета» исеме Гран-при иясе **«Include»**ка һәм татар телендәге **«Балалар дөньясы»** газетасына бирелде.

Бу конкурс – озын юлның беренче адымы. Икенче елга син дә катнашырга тырыш, дустым!

• Чыгарылыш-2014

# КФУның алтын фонды

**Башы 1нче биттә.**

25 июнь көнне КФУның чыгарылыш курс студентларыннан иң яхшыларына ректор И.Гафуров кызыл диплом тапшырды. Чарада яхшы укыган, шул ук вакытта университетның иҗтимагый тормышында актив катнашкан, уңышка ирешкән студентларны котладылар. «Сез укыган чор вакыйгаларга бай иде. Без Универсиада дигән искиткеч матур һәм зур бәйрәмнең шаһитлары булдык. Университетыбыздагы үзгәрешләрнең барысы да сезнең күз алдында узды. Боларның һәммәсе, әлбәттә, уку йортыбызның киләчәк үсеше өчен эшләнде. Сезнең зур тормышта югалып калмаячагыгызга ышанычым зур. Рәхмәт һәм уңышлар сезгә!» – диде үз котлавында И.Гафуров.

Ректорның җылы теләкләре, студентларның шат йөзләре, залда өстенлек иткән күтәренке рух бәйрәмне тагын да ямьле һәм тантаналы итте. Чыгарылыш курс студентлары, үз чиратларында, киләчәктә КФУның горурлыгы булырга сүз бирде. Чөнки Казан университеты студенты исеме аларны гомер дәвамында озатып барачак. Бу исемне лаеклы дәрәҗәдә йөртү, университетның данына тап төшермәү – аларның изге бурычы. Тормышта гомер буена истә калырлык вакыйгалар була. Ректор кулыннан кызыл диплом алган мизгелләрне студентлар киләчәктә дә сагынып искә алыр, дип ышанасы килә.

• Кабул итү – 2014

Кичәге студентлар – бүген инде югары белемле белгечләр. Уку йортыбыз аларның һәркайсын олы тормыш юлына хәер-фатихасын биреп озатып кала. Ә икенче яктан хыял-максатларын тормышка ашырырга җыенучы, зур тормышка аяк басучы кичәге абитуриентларны үз канаты астына ала. 20 июнь көнне университетыбызда Кабул итү кампаниясе үз эшен башлап җибәрде.

# Син дә КФУ студенты бул!

Илмир ВӘЛИЕВ,
Математика һәм механика институты

Уку йортының икенче корпусында урнашкан Кабул итү комиссиясендә урак өсте җәйнең беренче аенда башлана. Быелгы кабул итү тәртибе узган елдагыдан әллә ни аерылмаса да, 2013 елның 1 сентябреннән «Мәгариф турында»гы канун кысаларында яңа федераль таләпләр һәм югары уку йортларына яңа кабул итү тәртибе көченә кергән.

КФУ Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе Сергей Ионенко сүзләре буенча, узган елдан аермалы буларак, быел льготаларга ия гражданнар өчен квота кертелә, ягъни уку йорты үзенчәлекле хокукка ия булган, мәсәлән, инвалид балалар яки ятимнәр өчен квота кертү хокукына ия. Бу категориягә төрле олимпиадаларда җиңүчеләр дә керә. Ләкин аларның профиль фәннәре буенча БДИ нәтиҗәләре 65 баллдан да ким булмаска тиеш. Шулай ук, быел түләүле бүлеккә керүчеләр өчен аттестатның төп нөсхәсен бирү мәҗбүри түгел.

2014 елгы Кабул итү кампаниясенең тагын бер үзенчәлекле ягы бар: БМО иллә-реннән абитуриентларны кабул итү киңәйтелгән. «Бу бик тә мөһим, чөнки КФУда укучы чит ил гражданнарының артуы уку йортының үсеш стратегиясенә җавап бирә», – ди С.Ионенко.

Институт, факультетлардагы конкурс, башка еллардагы кебек үк, бик зур. Кабул итү комиссиясе әгъзалары быел биграк тә IT-технологияләр (фундаменталь информатика, гамәли информатика, мәгълүмати технологияләр), А.М.Бутлеров исемендәге Химия институтына конкурсның югары булуы турында әйтәләр. Елдагыча, икътисад, юриспруденция белән бәйле белгечлекләргә дә гариза тапшыручылар күп.

Документларны өч юл белән тапшырырга мөмкин: ***abiturient.kpfu.ru*** адресы буенча электрон вариантта, почта аша һәм шәхсән үзең китереп бирергә була. Беренче юлны уңайлырак дип санасалар да, шәхсән китереп бирүчеләр дә аз түгел. Ә Кабул итү комиссиясе 25 июльгә кадәр эшләячәк.

Һәр көнне кабул итү комиссиясендә абитуриентлар документларын тапшырырга чират торалар. Абитуриентлар КФУның кайсы юнәлешләренә өстенлек бирә икән? Кайберләре белән мин дә сөйләшеп алдым.

● *Ләйсән Нургатина:* «Мин документларымны Психология һәм мәгариф институтына тапшырдым. Киләчәктә югары категорияле психолог булырга телим. Балларым аз түгел, керә алырмын дип уйлыйм. Шулай да документларымны башка уку йортларына да биреп карыйм».

● *Нәфисә Исмаева:* 10 сыйныфтан КФУга керергә хыяллandым. Быел хыялым тормышка ашар дип уйлыйм. Гаризамны Икътисад һәм финанслар институтына бирдем. Алдагы тормышымны икътисад белән бәйләргә телим».

● *Луиза Муртазина:* «Гаризамны юридик факультетка тапшырдым. Конкурс зур булса да, керермен дип уйлыйм, чөнки балларым югары».

Булачак студентларга уңышлар теләп калыйк. «КФУ студенты» дигән дәрәҗәле исемне йөртергә язсын аларга!



Влад Михневский фотосы

● Хәтер яңартканда

# Яшьлеккә кайту

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты

Студент еллары һәрберебезнең күңелендә матур хатирә булып саклана. Казан университеты Тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген 1974 елда тәмамлаган чыгарылыш курс студентлары өчен дә бу шулай. Быел аларның университетны тәмамлауларына – 40 ел.

Мондый үзенчәлекле җыенга академик төркем җитәкчесе, Казан университетында озак еллар буе гарәп телен укыткан Лена Кәлимулла кызы Таҗиева да килгән иде. Ул – төркемнең әнисе, дисәк тә, ялгыш булмас. Студентлары аны бүген дә зурлап, хөрмәтләп яши. 1974 елда тәмамлаган чыгарылыш курс студентларының һәрберсе – шәхес. 5 ел буе бергәләшеп утнысуны кичкән, лекцияләр тыңлаган, имтиханнар тапшырган сабакташлар бүген дә аралашып яши, үзара элемтәдә тора. Университетны тәмамлагач, күбесе укыган юнәлешләре, алган һөнәрләренә тугрылыклы калган, үз балаларына да татар теле, тарихына карата мәхәббәт тәрбияләргә тырышкан. Мисалга, Альберт Тәхәвиев гомере буе нәшрият, журналистика өлкәсендә хезмәт куйган. Заманында «Идел» журналы мөхәррире урынбасары булып торган. «Без укыган чор университетның алтын чоры булды. Безгә Х.Госман, И.Нуруллин, Г.Саттаров, Ф.Сафиуллина, С.Ибраһимов, Д.Тумашева, М.Мәһдиев кебек чын зыялылар белем бирде», – дип искә ала Альберт әфәнде.



Күренекле шагыйрә **Шәмсия Җиһангирова** да шушы төркемдә белем алган. Ул да университет елларын сагынып, яратып искә ала. Университетта чыгып килгән «Әллүки» стена газетасының мөхәррире вазифасын башкарган, хорга, тынлы оркестрга йөргән. Ул: «Борылып карагач, 40 ел узганына ышанасы да килми. Бервакыт блокнотыма: «Әгәр дә мин Казан университеты Тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кермәгән булсам, Мөхәммәт ага Мәһдиев лекцияләреннән мәхрүм калган булыр идем», – дип язып куйганмын. Без укыганда, татар теленә мөнәсәбәт начар иде. Татар бүлегендә укучы студентларның билгесез киләчәге турында да сүзләр йөрде. Әмма бүген, еллар узгач, бу бүлектә укуыма сөенеп туя алмыйм. Әгәр мин биредә белем алмаган булсам, телебезгә бу кадәр дәрәҗәдә мәхәббәт булыр иде микән, дип шикләнеп куям. Мин бу мәхәббәтне бүген балаларыма гына түгел, оныкларыма да ирештерә алам» – дип, кичерешләре белән уртаклашты.




**Рәкыйбә Миргалимова** исә Чирмешән районы Бәркәтә мәктәбендә 40 ел буе татар теле һәм әдәбияты, тарих, җәмгыять белеме укытучысы булып эшли. Университетның үзенә дә, белем биргән укытучыларына да, алган һөнәренә дә рәхмәтле ул.

Фәлсәфә фәннәре докторы, ТР Фәннәр Академиясе эшләре идарәчесе вазифасын башкаручы **Фәрит Солтанов** төркем старостасы булган. Бүген дә ул – төркемне җыючы, берләштерүче. Ул төркемдәшләре Фәннур Сафин, Наис Гамбәр, Фәридә Гаффарны искә алды. Ни кызганыч, тик алар инде гүр иясе.

**Әнисә Алиева** – филология фәннәре кандидаты, Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. Хәзерге көндә ул милли мирасны халыкка җиткерү өлкәсендә күп көч куя. Татар классикларының әсәрләрен эзерләп бастыру белән шөгыльләнә.

**Илгизәр Сабиров** Яр Чаллыда яши. Озак вакыт мәктәптә укытучы, директор булып эшли, Тукай районының «Якты юл» газетасы редакциясендә хезмәт куя, соңрак мәдрәсә җитәкли. Бүген ул бер колледжда хуҗалык мәсьәләләре буенча директор урынбасары вазифасын башкара. Ул да университетта укыган һәм тулай торакта яшәгән күңелле яшьлек елларын сагынып искә ала.

Төркемдәшләрнең бер өлеше фән юлын сайлаunion, икенчеләре гомерен укытучылыкка багышлый. Мисалга, **Әлфинур Гаязова** Казанның 144 мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыта. Әмма аңа кадәр ул Казан радиоэлектроника институтында 17 ел буе инженер булып эшләгән.

**Зәния Гарифуллина** да 30 елдан артык Буаның 2 лицеенда татар теле укыткан. Ул чакта да университеттә чит тел өйрәнү мөмкинлеге булган. Зәния ханым француз телен сайлаган һәм бу уңайдан үкенү хисләре кичерә: «Төркемебез кураторы гарәп теле укытучысы булуына карамастан, француз телен укыдык. Яңадан укырга туры килсә, мин, һичшиксез, гарәп телен өйрәнгән булыр идем». Гарәпчә укырга Зәния ханым университетта түгел, лаеклы ялга чыккач, мәдрәсәгә йөреп өйрәнгән. Бүген Коръәнне оригиналда укый ала.

Сабакташлар очрашуы университет елларына бәйле хатирәләрне яңарту гына түгел, ә яшьлеккә кайту да. Минемчә, тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген 40 ел элек тәмамлаган чыгарылыш курс студентлары да очрашуда нәкъ менә шундый хисләр кичергәндер.

● Сәяхәттән кайткач

# Без – бердәм татар халкы!

**Айгөл ГАЛӘВЕТДИНОВА,** Филология
һәм мәдәниятара багланышлар институты

Себер, Себер туфрагы, Себер җире, Себер җилләре... Әйе, безгә дә, татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең икенче курс студентларына, Себер җирләрен таптап, Себер һавасын сулап, Себер суларын эчеп карарга насыйп булды. Татар теле һәм укыту методикасы кафедрасы профессоры Ф.Й.Йосыпов, доцент Д.Х.Хөснетдинов җитәкчелегендәге экспедициябез гаҗәеп кызыклы һәм мавыктыргыч үтте.

### *Чын авыл белән танышу*

Без Вагай районының Аусак авылында... Тирә-якта сазлык, юллар юк, кәрәзле телефон тотмый... Билгеле, килеп төшкәч, бу күренеш һәрбарчабызны борчуга салды. Үзебезне чыгып булмастай бер утрауга эләккәндәй хис иттек, сулышларны ачып



җибәрерлек саф һава әлеге халәтне йомшарта төшкәндәй булды. Ә Аусакның иң зур байлыгы – аның кешеләре.

«Сазлык арасындагы авылда да мондый кешеләр булыр икән?!» – дип гаҗәпләндем. Алар да эшләргә, яшәргә тырыша. Бездә җәй эшнең иң кызган чагы булса, Аусаклылар өчен кыш – еллык запас җыеп калдыру өчен иң кулай вакыт. Кышын боз өстеннән көндәлек кирәк-ярагын, бензинын, күмерен, йорт җиһазларын, төзү материалларын алып кайталар. Тормышлары авыр аларның. Ә бит, моңа карамастан, алар кешелеклелек сыйфатларын югалтмаганнар. Алардан да сабыр, алардан да тыйнак, алардан да эчкерсез адәм балалары булырмы икән җир йөзендә?

### *Һәркайсы – тарих*

Безнең төп бурыч – Себер татарларының сөйләшен өйрәнү, аларда булган диалектал лексиканы барлау, яшәү рәвешен, борынгыдан килгән гореф-гадәтләр белән танышу иде. Олы яшьтәге апа-абыйлар авыл тарихларын, риваять-легендаларны, Коръән ашлары, бәбәй ашлары һ.б. хакында бәйнә-бәйнә, чын күңелләреннән бирелеп сөйләделәр. Һәрберсенең сүзен түкми-чәчми диктофонга яздырып, дәфтәр битләренә теркәп бардык. Кәнозын мәгълүмат туплап, кичләрен шуны тәртипкә сала идек.

Шулай бер кич, җыйнаулашып, язмаларны эшкәртеп утырабыз... Кичке тынлык... Бервакыт тәрәзә артында егетләр тавышы ишетелде. Аусак егетләре килгән. Билгеле, куркуга төштек. Авылда әле кыз урлау йоласы яшәп килә икән. Бу хәл берничә мәртәбә кабатланды. Ходайга шөкер, хәвеф-хәтәрсез әйләнеп кайттык.

### *Бәйрәм ашы – кара-каршы*

Без дә, Аусак халкының күңеленә ничек тә булса кереп калыйк дип, татар халкының милли бәйрәмен – балалар өчен Сабантуй оештырдык. Аларда, гомумән, әлеге бәйрәм билгеләп үтелми икән. Моның сәбәбе шунда: аларда иген чәчү, үстерү өчен уңдырышлы җирләр, басу-кырлар, кызганычка каршы, юк. Авыл тарихында беренче тапкыр үткәрелсә дә, әлеге бәйрәм халык күңеленә хуш килде.

Кунак ашы – кара-каршы, дигәндәй, Аусаклылар безне «Ерак араларны якын итеп, хуш киләсез, туганнар!» дип исемләнгән концерт белән сөендерделәр. Һәрберсе җырлый, бии... Гаҗәеп дәрәҗәдә талантлы кешеләр.

### *Мең яшәгез, Аусаклылар!*

Алар да бит татарлар, беренче карашка, бездән берни белән дә аерылып тормаска тиешләр кебек. Алай түгел икән шул. Алар – Себер татарлары – үз сөйләше, яшәү рәвеше, гореф-гадәте һәм йоласы булган халык.

Шулкадәр ияләштек без андагы авыл кешеләренә, аларда нindидер үзләренә тарту көче бар. Шуңа күрә хушлашу мизгелләре авыр булды. Белмим, бәлки, кунакчыл, эчкерсез булулары үзләренә шулай тартадыр да.

Күпме гыйбрәтле язмышлар, тарихи вакыйгалар, борынгыдан килгән фольклор үрнәкләре... Искиткеч! Бу экспедиция фәнгә кереп китү өчен юллама гына бирепе калмады, безне рухи яктан баетты, җанкардәшләребез белән аралашу мөмкинлеге тудырды. Шушы чараны оештырган җитәкчеләребезгә дә зур рәхмәтебезне җиткерәбез.

**Таныш бул!**

# «Укытудан ләззәт алам...»

**Гүзәлия ГЫЙНИЯТУЛЛИНА**, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Мода артыннан куарга ярата торган җәмгыятебездә ана теленә карата мөнәсәбәтнең тискәре якка үзгәрә баруы беркем өчен дә сер түгел. Ләкин халкыбызның гореф-гадәтләрен, традицияләрен, милли йолаларын саклап калу өчен көрәшүчеләр, татар телен үстерергә теләүчеләр бик күп. Алар рәтендә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты, шул ук вакытта татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлназ Владимир кызы Гатауллина да бар. Аның белән булган әңгәмәмне сезнең игътибарга да тәкъдим итәм. Хәзерге көндә мәктәпне тәмамлап, тормышның һөнәр сайлау этабына баскан абитуриентлар өчен дә, яшь укытучылар өчен дә аның киңәшләре комачау итмәс.



**– Гөлназ, балачагың белән таныштырып кит әле.**

- Мин Башкортстан Республикасының Дүртөйле районы Түбән Әлкәш авылында туып үстем. Балачак, мәктәп елларын бик яратып һәм сагынып искә алам. Кечкенәдән үк укырга яраттым. Китапханәдә укылмаган китап калмады бугай инде. Дәү әтием – гармунчы. Авылда, районда нинди генә бәйрәм булса да, дәү әти тальян гармунын тотып чыгып китә иде. Җыр-моңга гашыйк булып үстем, җырларга, биергә өйрәнәсе килә иде, тик бу юнәлештәге түгәрәкләргә йөрү бәхете тимәде. Шулай да, дәү әти гармунда уйнарга өйрәтә иде. Әле дә зур теләк белән халык җырларын тыңлыйм, җырларга да, биергә дә өйрәндем. Милли тәрбия алуым белән, беренче чиратта, әбибабаема бурычлы.

**- Гөлназ, укытучы һөнәрен сайларга нәрсә этәрде?**

- Татар теле һәм әдәбият дәресләренә мәхәббәт уяткан укытучым Мәмдүдә Флүр кызы минем язмышымда мөһим роль уйнады. 8 сыйныфта укыганда, укытучым үзенә чакырып алды да, татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиада, конкурсларда катнашырга тәкъдим итте. Көн-төн әзерләнүләр, конкурстан конкурска, олимпиададан олимпиадага йөрүләр үз юлымны сайларга, Казанга укырга керү хыялын тормышка ашырырга ярдәм итте. Казан университетының татар филологиясе бүлеге студенты икәнлегемне белгәч, беренче булып сөенечемне әнигә түгел, ә укытучыма әйттем. Укытучы булу теләгем - остазым Мәмдүдә Флүр кызы кебек булырга теләвем иде ул.

**- Син - яшь укытучы. Дөресрәге, студент-укытучы. Бу дәрәҗәгә син ничек ирештең? Мәктәпләргә тәҗрибәсез, бигрәк тә студентларны бик сирәк очракларда гына эшкә алалар бит.**

- Әйе, чынлап та, бу бик авыр. 2013 елның җәендә укыту эше кызыктыра башлады. Балалар белән эшләүнең нәрсә икәнен яхшы беләм, моңа кадәр лагерьларда әйдаман булып эшләгәнем булды. Мәктәпкә тартылуымда дусларымның да йогынтысы булгандыр инде. Бергә торган кызлар мәктәптә укыталар иде. Аларга кызыгып, эш эзли башладым. Ләкин мәктәпләр миндә бер дә өмет чаткысы уятмады. Шулай вакансия эзләп утырганда, чәчтарашханәгә педагог таләп ителә дигән вакансиягә юлыктым. Заманында парикмахер-универсал курсын тәмамлаган идем. Бардым - алдылар!

**- Әмма син хәзер татар теле дә укытасың бит. Ничек?**

- Мәктәп турында инде онытып бетергәч, социаль челтәрдә «татар теле буенча укытучы эзлибез» дигән игъланга төртелдем. Шалтыратып әңгәмәгә язылдым. Күреп сөйләшүгә, эшкә чакырдылар. Бу христиан мәктәбе булып чыкты. «Краеугольный камень» чиркәве нигезендә ачылган уку йорты. Ике атна эчендә ике эшле булдым.

**- Беренче вакытларда авыр булмадымы? Коллектив, балалар ничек кабул итте?**

- Мәктәптә - рус балалары. Татар телен бөтенләй белмиләр иде. Бик теләп, кызыксынып өйрәнә башладылар. «Безгә татар теле кирәкми», - дигән фикерләр дә булгалады. Аннары алар да кызыксынып укый башладылар. Коллектив бик яхшы, һәрчак ярдәм итәләр, белмәгән чакларда киңәшләр бирәләр. Университетта методика дәресләрендә өйрәнгәннәрне шунда ук практикага кертеп бардым. Беренче көннәрдә төп проблема шул булды: 45 минутка сыешып бетә алмый идем. Әкренләп кереп киттем, өйрәндем.

**- Синеңчә, хәзерге заман укытучысы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

- Укучылар, иң беренче чиратта, укытучының тышкы кыяфәтенә, үз-үзен тотышына, җитдилегенә игътибар итә. Аннан соң гына эрудиция, холык кебек әйберләрне ача башлыйлар. Укытучы һәрвакыт эталон булып калырга тиеш. Заман белән бергә атлау да мөһим роль уйный. Укыту предметыннан тыш, әлбәттә, яшьләр нәрсә белән кызыксынганын, нинди карашлар белән яшәгәнен белсә яхшы. Шәхсән, бу сыйфатлар миңа балалар белән уртак тел табарга ярдәм итә. Балалар белән эшли башлаганда, әни бер киңәш бирде: «Үзең балалар белән эшләгәндә, укытучыларың ясаган хаталарны беркайчан да кабатлама!» – диде.

**- Укучыларың туган телне яратып өйрәнәме?**

- Әйткәнемчә, мин рус һәм башка милләт укучыларына татар теле серләрен өйрәтәм. Аларга татар телен, грамматиканы аңлатканда, еш кына чит телләр белән чагыштырып күрсәтәм, инглиз, төрек, гарәп, алман телләренә кереп чыгам. Аларга тагын да кызыграк. Гомумән, фәнне яратып өйрәнү ул укучының мөмкинлекләреннән һәм ирешкән уңышларыннан тора. Икеле белән өчле арасында йөргән бала белән бер утырып индивидуаль дәрес үткәрүең, мактап алуың була, икенче дәресләрдә ул инде күпкә яхшырак эшли. Иң мөһиме, баланың «моннан барыбер берни дә чыкмый» дип канатларын кисмәскә.

**- 21 гасыр балаларын гаҗәпләндерерлек нәрсәләр бар?**

- Хәзерге балаларны гаҗәпләндерү җиңел түгел. Алар укытучыдан да күбрәк белә. Мин аларны төрле мәдәни чараларга еш йөртәм. Өлкән яшьтәге укытучылар андый җирләргә йөреп туйган инде. Балаларны мәдәниятькә якынайтырга, аларның рухи байлыкларын үстерергә һәм сәләтләрен ачарга мөмкинлекләр булганда ник йөртмәскә? Укучылар белән «Мин татарча сөйләшәм» чарасы кысаларында «Татар-дозор-2014» дип аталган квест-уенында катнашып, призлы урыннар алдык.

**Гөлназ – алдынгы карашлы яшь шәхес, актив тормыш алып бара. Мәктәптә - татар теле, «Malbakh-Fashion» компаниясендә – чәчтараш белгечлеге буенча педагог. Ике югары белем ала. Берсе татар филологиясе юнәлешендә булса, икенче белеме - икътисадчы икән. Шуңа өстәп, Бөтендөнья татар яшьләре форумының координаторы да. Алга таба да планнары шактый. «Минем кечкенә чагымда кем генә буласым килмәгән икән. Укытучы, чәчтараш, биюче, янгын сүндерүче, табиб, фигуралы шуу карасам, фигуристка буласым килә иде... Хыяллар әкренләп чынга аша... Табиб һөнәре белән фигуралы шуу гына чынга ашмады. Әлегә», – дип серле елмая Гөлназ.**

**Тәңгә - мунча, җанга - юк**

# Компьютер һәм бала

**Гөлгенә ИДРИСОВА**, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты



Бүгенге көндә үзебезне компьютердан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Компьютер интернеттан теләсә нинди сорауга җавап табарга, социаль челтәрдә дуслар белән аралашырга мөмкинлек бирә. Кыска гына вакыт эчендә кеше үзенә кирәкле мәгълүматны таба. Ләкин, уңай яклары күп булган кебек, компьютерның зыяны да шактый. Бу, бигрәк тә, чамасын белеп кулланмаганда нык сизелә.

Кызганыч, XXI гасыр баласы, урамда саф һавада уйнауга караганда, өйдә компьютер алдында утыруны кулайрак күрә. Кеше организмының физик, рухи, эмоциональ һәм интеллектуаль яктан үсеш чоры нәкъ менә яшь вакытка туры килә. Шуңа күрә, компьютер алдында озак утыру баланың үсешен югарыда санап киткән барлык критерийлар буенча артта калдырырга мөмкин, дигән уй туа.

Физик яктан караганда, компьютер алдында озак утыру гиподинамиягә һәм умыртка баганасының кәкрәюенә китерә. Спорт белән шөгыльләнү, саф һавада футбол, волейбол кебек актив уеннар уйнау яки велосипедта йөрү урынына сәгатьләр буена монитор каршында утыручы балалар, нәтиҗәдә, йомшак мускуллы, бөкре, тиз аручан, физик активлыгы түбән һәм тиз кызып китүчәнгә әйләнергә мөмкин. Күзләргә дә зыяны зур. Ким дигәндә, астигматизм булса, алга таба күз күременең начарлана баруы, тагын да куркынычрак авыруларга юлыгу мөмкинлеге бар.

Экраннардагы негатив мәгълүмат импульслар эмоциональ яктан әле формалашып кына килә торган организмга тагын да зур зыян сала. Виртуаль аралашу чынбарлыктагы, реаль тормыштагы аралашуны кысрыклый. Мәгълүматны тиз һәм әзер килеш алу баланың үзлектән мөстәкыйль эшләвен, ягъни интеллектуаль яктан үсешен чикли.

Интернеттагы төрле сайтлар, культ, субкультура, ритуаллар турындагы мәгълүмат баланың рухи яктан үсешенә шактый дәрәҗәдә зур зыян китерә. Дөрес, кайбер сайтларда +18 тамгасы тора, ләкин әлеге сайтка керү әллә ни авырлык тудырмый. Шулай ук, битне ачуга, төрле оятсыз темага фото, рәсем, анимацияләр баланы бик тиз кызыктыра.

Бала интернет «колы» булмасын өчен нишләргә кирәк соң? Беренчедән, вакытны контрольдә тоту мәҗбүри булырга тиеш. Бала компьютер алдына бик кирәк чакта гына утырсын. Мәсәлән, мәктәп журналына керү, дәрескә әзерләнү (презентация, документ, клип ясау), кирәкле материал алу өчен. Монитор каршында утыру 15 минуттан артмаска тиеш, әгәр бала әлеге вакыт эчендә өлгермәсә, компьютер алдыннан китеп, бераз ял итеп алсын. Икенчедән, баланың буш вакытын файдалы оештырырга кирәк. Актив уен формаларын, китап уку, рәсем ясау кебек шөгыльләр белән аралаштырырга була. Ә иң мөһиме, ата-ана компьютерны балага караганда яхшырак үзләштерергә тиеш. Кызганыч, күп очракта, бу күренеш киресенчә шул... Баланың үз белдегә белән кереп, интернетның бөтенләй кирәкмәгән функцияләрен ачуы ихтимал.

Замана таләпләре шундый: баланы компьютердан бөтенләй аерып алу дөрес түгел, билгеле. Ләкин, файдасына караганда зыяны артык булмасын өчен, гади кагыйдәләрне үтәү мәҗбүри.

*P.S. Сөйләгәннәрем тапталып беткән мәгълүмат булса да, укучыларның җәйге ялы башланган чорда һәр киңәш урыны һәм файдалы булыр дип уйлыйм. Балаларга гына түгел, үзебезгә дә аларга колак салсак, комачауламас иде.*

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.